ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваш авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

08.11.2023 с. Старое Русское Маматкозино 02

Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнардан үзара салым җыю һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 400 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрен) төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Мәмәтхуҗа мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча халык җыенын үткәрергә: Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Юл урамы, 1 йорт 11.00 сәгатьтә.

4. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В.В.Никитушкин